Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл
җирлеге Советы

**КАРАР № I**

Котлы-Бөкәш авылы                    2022 елның 28 марты

Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 маддәсендәге 3 пункты нигезенд Котлы-Бөкәш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым, бу салымнар буенч пенялар һәм штрафлар буенча недоимканы түләттерүгә өметсез дип тануны түбәндәге очракта өстәмә нигезләрен билгеләргә:

варислар мираска хокуктан баш тарткан очракта, варислар булмау яки мира малы ачылганнан соң бер ел эчендә мирас алынмау очрагында вафат булган яис үлгән дип игълан ителгән физик затларның недоимкасы, пенялар һәм штрафла буенча бурычы булу.

2. Җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча недоимкан түләттерүгә, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез ди тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып тора:

физик затның яшәү урыны буенча салым органының недоимка һәм пенялар һә штрафлар буенча бурычлар турында белешмәсе;

физик затларның гражданлык хәле актларын теркәүне гамәлгә ашыручы орга тарафыннан физик затның үлеме фактын теркәү турында белешмәләр;

мирас хокукы турында таныклык бирү хакында белешмәләрнең булмав турында салым органы белешмәсе.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән) соң ү көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга : Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмле Казаклар Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Нәҗипов